ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_10.03.2021_ с. Муслюмово №__110____

**Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслаучы карарларның үз көчен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 26 ноябрендәге 7036 номерлы, 2020 елның 24 декабрендәге 7483 номерлы, 2021 елның 15 гыйнварындагы 7507 номерлы, 2021 елның 26 гыйнварындагы 7522 номерлы күрсәтмәләре, «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опекун (попечитель) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (түләүле яисә түләүсез шартларда) яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 02 декабрендәге под-1148/20 номерлы боерыгы, «Банкта яки башка кредит оешмасында счеты (кертем) булган балигъ булмаган балаларның счетын ябу, исәптән салдыру, күчерү, куллану өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 05 ноябрендәге под-1158/20 номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 декабрендәге под-1326/20 номерлы боерыгы, «Балигъ булмаган затларның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга башлангыч рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 9 декабрендәге под-1305/20 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 4 гыйнварындагы 16/21 номерлы, 2021 елның 21 гыйнварындагы 567/21 номерлы, 2021 елның 22 гынварындагы 645/21 номерлы, 2021 елның 20 февралендәге 1891/21 номерлы хатлары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм

попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслый торган түбәндәге карарлар үз көчләрен югалткан дип танырга:

– «Балигъ булмаган баланың акча кертемен алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 23 июнендәге 334 номерлы карары;

– «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле һәм түләүсез шартларда) ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) билгеләү, яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 23 июнендәге 334 номерлы карары;

– «Балигъ булмаган затларның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга башлангыч рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 336 номерлы карары;

– «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 337 номерлы карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе Р.Т. Демидов**